**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИЖЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

28.07.2026 ел № 14

Менделеевск муниципаль районының
Ижевка авыл җирлеге территориясендә
стационар булмаган сәүдә объектларын
урнаштыру схемасын раслау турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын кушымта нигезендә расларга.
2. Биш көн эчендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруның күрсәтелгән схемасын Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына тапшырырга.
3. Әлеге карарны җәмәгать урыннарындагы мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Ижевка авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам

Ижевка авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Мәсәгутова

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль
районы Ижевка авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2026 елның 28
июлендәге 14 нче номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № п/п | Стационар булмаган сәүдә объектларының урнашу урыны исеме | Сатыла торган товар ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объектлары тибы (павильон, киоск, автомагазин, автолавка, тонар, лоток контейнер, бакча разваллары) | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының стационар булмаган сәүдә объектларыннан файдалануы | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Ижевка авылы, Совет ур.<br><br>«На Советской» кибете янында | Азык-төлек, кием, аяк киеме, хуҗалык товарлары, уенчыклар, үсентеләр, орлыклар, тере кошлар, кошлар һәм хайваннар өчен азык | Автомагазин, автолавка | кулланыла | Ел әйләнәсе |